ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
Сарман авыл жирлеге

Сармановское сельское поселение
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

07 август 2025 ел № 13

Сарман авыл җирлеге Башкарма комитетының 05.04.2023 ел, № 5 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең "Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турындагы нигезләмәне раслау хакында" 14.03.2024 No 300 карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Сарман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» 05.04.2023 ел, № 5 карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

Карарның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында мәгълүмат әйләнә-тирә мохит торышы федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында (стойкаларында) урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Л.И.Шәрипова